ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.03.2020 № 117

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 20 февралендәге 136 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хөкүмәтнең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2019 елның 28 декабрендәге 1934 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 20 февралендәге 136 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү һәм аларны гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу тәртибенә (алга таба-тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 2 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «объект дәрәҗәсендә - халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен билгеләнгән һәм җәлеп ителә торган көчләр һәм чаралар белән идарә итү, гадәттән тыш хәлләр турында халыкка мәгълүмат алмашу һәм хәбәр итү өлкәсендә аларның эшчәнлеген тәэмин итә торган оешмалар бүлекчәләре»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Л.Н. Маняпов